ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13 03 2023 г. № 192

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 342-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 бүлектәге 2.5.1 пунктына (4 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, Регламентының 2.5.1 пунктындагы 8 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы».

түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) мондый килештерү шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган очракта, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү;»;

5 һәм 9 пунктчаларның үз көчен югалтуын танырга;

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә

бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә. Хаҗиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов